РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

10.05.2023 № 593-п

Татарстан Республикасы Саба муниципаль
районының гомуми файдаланудагы җирле
әһәмияттәге автомобиль юлларына юл сервисы
объектларын кушу буенча хезмәтләр күрсәтү
бәясен һәм исемлеген билгеләү турында

«Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2007 елның 8 ноябрендәге 257-ФЗ номерлы Федераль законның 13 һәм 22 маддәләре, «Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» 2009 елның 03 августындагы 43-ЗТР номерлы Татарстан Республикасы Законының 13 маддәсе нигезендә Саба муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына юл сервисы объектларын кушу буенча хезмәт күрсәтү бәясен һәм исемлеген расларга (кушымта итеп бирелә).
2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында бастырып чыгарырга.

Саба муниципаль районы
Башкарма комитеты
Җитәкчесе М.Р.Ишниязов

Татарстан Республикасы Саба
муниципаль районы Башкарма
комитетының 2023 елның 10 маендагы
593-п номерлы карары белән
РАСЛАНГАН

**Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына юл сервисы объектларын кушу буенча хезмәтләр күрсәтү бәясе һәм исемлеге**

| т/б № | Хезмәтнең атамасы | III - V категорияле юлның бәясе, сумнарда |
|---|---|---|
| 1. | Җәмәгать туклануы пунктын (кафе, ресторан һ.б.), кибетне кушу | 35 803,68 |
| 2. | Техник хезмәт күрсәтү станциясен (шиномонтаж) кушу | 30 921,36 |
| 3. | Техник хезмәт күрсәтү станциясен (ремонт, юу урыны) кушу | 39 058,56 |
| 4. | Базарны кушу (сәүдәнең оешкан нокталары) | 39 058,56 |
| 5. | Транспорт чараларын туктату урыннарын һәм тукталыш урыннарын тоташтыру (юл сервисы объектларында) | 26 039,04 |
| 6. | Автомобильгә ягулык салу станциясен кушу | 47 195,76 |
| 7. | Юл сервисы комплексын кушу | 47 195,76 |
| 8. | Автомобильгә ягулык салу станциясе белән юл сервисы комплексын кушу | 56 960,4 |
| 9. | Сәүдә комплексы кушылу | 47 195,76 |
| 10. | Йөк автотранспортына хезмәт күрсәтүче биналарны һәм корылмаларны (йөк автомобильләре станцияләре, терминаллар, түләүле автомобиль туктау урыннары һ.б.) кушу. | 52 078,08 |